**Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение "Высокогорский детский сад "Сандугач" комбинированного вида Высокогорского муниципального района Республики Татарстан**

# СБОРНИК

## успешных образовательных практик реализации регионального компонента в Высокогорском районе

# «Всему начало здесь, в краю моем родном»



с. Высокая Гора 2025

Глобальләшү һәм башка мәдәниятләр йогынтысы шартларында, үзенчәлекләрен югалтмас өчен, балаларга кечкенәдән үк үз тамырларына хөрмәт тәрбияләү мөһим.

Балалар бакчасында татар мәдәнияте белән танышу башка халыкларга карата ихтирамны үстерүгә, илебезнең мәдәни күптөрлелеген аңлауга ярдәм итә. Бу бигрәк тә күпмилләтле Татарстан Республикасында мөһим.

Икенче телне (рус телле балалар өчен татар телен яки киресенчә) иртә өйрәнү хәтерне, игътибарны, аналитик сәләтләрне стимуллаштыра. Билингвизм интеллектуаль үсешкә уңай йогынты ясый.

Федераль дәүләт белем бирү стандарты һәм Татарстан Республикасы законнары мәктәпкәчә белем бирүгә милли-төбәк компонентын кертүне күздә тота. Бу татар телен һәм мәдәниятне республиканың дәүләт теле буларак өйрәнүне үз эченә ала.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда еш кына аңлы рәвештә икенче телне өйрәнүгә ихтыяҗ юк. Белем бирү процессын кызыклы итү өчен иҗади якын килү, уен методларын куллану таләп ителә. Бу балаларда мотивация тудыра.

Гаиләләрдә татар телендә аралашу һәрвакытта да хупланмый, бу күнекмәләрне ныгытуны кыенлаштыра. Бу очракта балалар бакчасының роле - уеннар, җырлар, әкиятләр аша тел мохите булдыру. Барлык ата-аналар да татар телен өйрәнүнең мөһимлеген аңламый, ә кайберләре битараф яки хәтта каршы булырга мөмкин. Гаиләләр белән системалы эшләү кирәк: консультацияләр, ачык дәресләр, проектларга җәлеп итү.

Балалар грамматик конструкцияләрне әйтүдә, аңлауда кыенлыклар кичерергә мөмкин. Материалны яшь үзенчәлекләренә җайлаштыру таләп ителә.

Традицион алымнар һәрвакытта да нәтиҗәле түгел. Заманча технологияләрне: мультимедиа презентацияләрен, проект методын, театральләштерелгән уеннарны актуаль кертү.

Конспектларны уңышлы тормышка ашыру өчен уен алымнарын, ата-аналарны җәлеп итүне, этномәдәни компонентны (милли бәйрәмнәр, һөнәрләр, костюмнар) куллануны һәм уңай тел мохите булдыруны берләштерергә кирәк. Шулай ук балаларның индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алу һәм материалны аларның үсеш дәрәҗәсенә яраклаштыру мөһим.

Җыентыкта кыскача тәкъдим ителгән материаллар педагоглар тарафыннан эшләнде һәм сынап каралды.

Тәкъдим ителгән конспектлар мәктәпкәчә яшьтәге балаларны татар теленә һәм мәдәниятенә якынайту өчен шартлар тудыра, Татарстанның күпмилләтле мирасын алга таба өйрәнү һәм хөрмәт итү өчен нигез булдыра.



«Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны зур конструкторлар ярдәмендә татар теленә өйрәтү»
(Методические рекомендации для педагогов по обучению детей татарскому языку)

воспитатели: Аминова Г.Р., Гилязова А.И.

"Бабашки" — это крупные конструкторы, из которых дети могут строить конструкции в полный рост: мебель, домики, лабиринты, корабли.

Их преимущества для билингвальной среды:

1. Мотивация и эмоции: игра с такими крупными объектами вызывает сильный эмоциональный отклик. Язык становится не целью, а средством для достижения желаемого (построить, поиграть).

2. Естественная коммуникация: дети вынуждены договариваться, распределять роли, объяснять свои идеи. Это создает идеальные условия для естественного усвоения второго языка.

3. Тактильность и кинестетика: дети не просто слушают слова, они "пропускают их через руки и тело". Фраза «Давайте построим высокую башню» подкрепляется реальным физическим действием, что улучшает запоминание.

4. Проектная деятельность: работа с "Бабашками" — это всегда проект, где язык изучается в контексте решения конкретной задачи.

В билингвальной группе один воспитатель может говорить на русском, другой — на татарском (или другом целевом языке). Во время игр с "Бабашками" можно использовать метод "один человек — один язык" или погружать в язык целиком на время определенной активности.

Занятие 1. Тема: «Өй / Дом»

1. Кереш / Введение (5 минут):



Педагог собирает детей вокруг конструктора и на татарском языке представляет тему: «Бүген без өй төзибез!» (Сегодня мы построим дом!). Показывает детали и проговаривает:

- Бу зур кисәк, бу кечкенә кисәк. (Это большая деталь, это маленькая деталь).

2. Бирем бирү / Постановка задачи (3 минуты):

- Карагыз, бу нәрсә? Сез нинди өй төзергә телисез? Зур өйме, кечкенәме? (Смотрите, что это? Какой дом вы хотите построить? Большой или маленький?)

3. Эшләү процессы / Практическая работа (15-20 минут):

- Дети делятся на пары или маленькие группы.
- Педагог ходит между ними, помогая и комментируя на татарском:

- Мәдинә, зур түбә бир. Ильдар, тәрәзә урнаштыр. Бик матур өй! (Мадина, дай большую крышу. Ильдар, поставь окно. Очень красивый дом!)

Поощряются любые попытки детей повторить слова или сказать простую фразу на татарском.

4. Нәтиҗә / Рефлексия и презентация (5-7 минут):
Каждая группа представляет свою постройку. Педагог помогает с вопросами:



- Бу нинди өй?» (Этокакой дом?)

· В конце все вместе говорят: «Безнең өйләр матур! Без яхшы эшләдек!» (Наши дома красивые! Мы хорошо поработали!)

<u>Занятие 2. Тема: «Шәһәр / Город»</u>

1. Кереш / Введение (5 мин):
Педагог показывает детали и на татарском языке называет:

- Бездә төрле зурлыктагы һәм төрле формадагы детальләр бар. Әйдәгез алардан шәһәр төзик! (У нас есть детали разного размера и разной формы. Давайте из них построим город!)



2. Бирем бирү / Постановка задачи (3 мин):
- Безгә йортлары, юллары һәм күпере булган шәһәр төзергә кирәк. (Нам нужно построить город с домами, дорогой и мостом).

3. Эшләү процессы / Практическая работа (15-20 мин):
Педагог взаимодействует с ними на татарском, задавая наводящие вопросы и давая инструкции:

- Туры килгән детальләрне сайлагыз һәм төзи башлагыз. (Выбирайте подходящие детали и начинайте строить.)

Дети между собой могут общаться на русском, но в ответ педагогу стараются использовать татарские слова.

4. Нәтиҗә / Рефлексия и презентация (5-7 мин): Каждая группа представляет свою постройку. Педагог помогает с описанием на татарском языке:

- Карагыз әле, безнең шәһәр нинди матур булып чыкты! (Посмотрите, каким красивым получился наш город!)

<u>Занятие 3. Тема: "Строим дом / Өй төзибез"</u>



Лексика:

Русский: строить, дом, стена, крыша, окно, дверь, комната, кухня, спальня.

Татарча: төзү, өй, түбә, дивар, түшәм, тәрәзә, бүлмә, аш бүлмәсе, йокы бүлмәсе.

Деятельность / Эшчәнлек.

Воспитатель ставит задачу: "Давайте построим дом! / Әйдәгез өй төзибез!".

Задает вопросы на двух языках: "Что нам нужно для дома? / Өй төзү өчен безгә нәрсә кирәк?", "Где будет окно? / Тәрәзә кайсы җирдә булачак?".

Вводит глаголы: "Поставь этот блок выше. / Бу кисәкне өскәрәк куй. Подними, пожалуйста. / Күтәр, зинхар өчен. Держи. / Тот."

Игра: После постройки дети "заселяются" в дом и обыгрывают бытовые ситуации: "Я готовлю ужин на кухне. / Мин аш бүлмәсендә кичке аш әзерлим."

Занятие 4. Тема: "Транспорт и путешествия / Транспорт һәм сәяхәт итү."

Лексика:



Русский: машина, автобус, поезд, самолет, корабль, руль, колесо, лететь, ехать, билет.

Татарча: машина, автобус, поезд, самолет, корабль, руль, тәгәрмәч, очу, барырга, билет.

Деятельность / Эшчэнлек:

- Дети совместно строят транспортное средство.
- Воспитатель: "Куда мы поедем на этом автобусе? / Без бу автобуска утырып кая барабыз?". "Вам нужен билет? / Сезгә билет кирәкме?".

Можно создать целый "вокзал" или "аэропорт" с разными зонами

Занятие 5.Тема: "Зоопарк / Зоопарк"

Лексика:



Русский: животные, слон, жираф, медведь, клетка, вольер, кормить, охранять.

Татарча: хайваннар, фил, жираф, аю, читлек, вольер, ашатырга, сакларга.

Деятельность /Эшчәнлек:

- Дети строят вольеры для разных животных.
- Воспитатель: "Давайте построим высокий забор для жирафа! / Әйдәгез, жираф өчен биек койма төзик!", "Медведю нужна берлога. / Аюга өн кирәк ."

Ролевая игра: кто-то посетитель, кто-то смотритель зоопарка. Диалоги: "Этот слон большой! / Бу фил зур!", "Когда кормление? / Ашау вакыты кайчан?".

Занятие 6. Тема: "Геометрические фигуры и счет / Геометрик фигуралар һәм санау."



Лексика:

Русский: куб, кирпичик, цилиндр, большой/маленький, высокий/низкий, широкий/узкий, счет (1-10).

Татарча: куб, кирпеч, цилиндр, зур/кечкенә, югары/түбән, киң/тар, санау(1-10).

Деятельность / Эшчэнлек:

Соревнование / Ярыш: "Построй самую высокую башню! / Иң биек манара төзе!".

Воспитатель: "Сколько кубиков ты использовал? / Син ничә кубик кулландың?", "Дай мне, пожалуйста, два цилиндра. / Миңа ике цилиндр бир, зинһар.

Занятие 7. Тема: "Спасательная станция / Коткару станциясе"



1. Введение (5-7 мин):

Воспитатель показывает картинки спасателей: пожарных, врачей. Обсуждает, что они делают.



Воспитатель (на татарском) вводит ключевые слова: коткару, булышу, янгын сүндерү машинасы, хастаханә, кызу!

2. Задача и планирование / Бурыч һәм планлаштыру (5 мин):

- Ребята, нам нужно построить спасательную станцию! / Балалар, безгә коткару станциясе төзергә кирәк!".



Обсуждение на двух языках: "Что должно быть на станции? Гараж для машин? Больница? / Станциядә нәрсә булырга тиеш? Машина өчен гараж? Хастаханә?".

3. Строительство / Төзелеш (15-20 мин):

Дети делятся на группы и строят. Воспитатели активно участвуют, комментируя действия и помогая фразами на двух языках: "Бу дивар тирбәлә, әйдәгез аны ныграк итик! / Эта стена шатается, давай сделаем ее крепче!", "Безгә янгын сүндерү машинасы өчен зур ишек кирәк! / Нам нужна большая дверь для пожарной машины!".

4. Сюжетно-ролевая игра / Сюжетлы-рольле уен (10-15 мин):

· Дети получают роли: пожарные (янгын сүндерүчеләр), врачи (табиблар), диспетчеры (диспетчерлар).

· Воспитатель создает "чрезвычайную ситуацию": "Песи агачта! / Кот на дереве!", "Урманда янгын чыккан! / В лесу пожар!".



· Дети действуют, используя изученную лексику в диалогах.

5. Рефлексия / Нәтиҗә (5 мин):

· "Что мы построили? Кому мы помогли? / Без нәрсә төзедек? Без кемгә ярдәм иттек?".

· Похвала на обоих языках: "Сез бүген бик яхшы төзүчеләр һәм коткаручылар булдыгыз! / Вы сегодня были отличными строителями и спасателями!".

***Заключение***

Сочетание билингвального подхода и ростовых конструкторов "Бабашки" — это мощный инструмент в руках современного педагога. Оно позволяет:

- Снять языковой барьер через действие и игру.
- Развивать коммуникативные навыки на двух языках.
- Стимулировать когнитивное, социальное и физическое развитие.
- Сделать процесс изучения второго языка радостным и незабываемым для дошкольников.

"Сөмбелә"
(Зурлар төркеме өчен бәйрәм сценариясе)

Тәрбияче: Зарипова З. И., Нуриева М. М.

**Алып баручы:** Исәнмесез, кадерле кунаклар! Исәнмесез, балалар! Балалар, карагыз әле, бөтен җир кызыл-сары яфраклар белән тулган. Ни өчен?

Кем бизәгән аны? Әйе, көз килгән.Һәр ел көз белән бергә уңыш бәйрәме дә килә, ә уңыш бәйрәме белән бергә Уңышбикә-Сөмбелә дә. Әйе, без бүген халкыбызның бик матур бәйрәмнәренең берсе - "Сөмбелә" бәйрәменә җыелдык. Ә нинди бәйрәм соң ул һәм ни өчен аны «Сөмбелә» дип атыйлар.

Безнең ата - бабаларыбыз Сөмбеләне уңыш җыеп алу ае итеп кенә түгел, ә шул айның иясе һәм уңыш-уңдырышлылык алиһәсе итеп тә күз алдына китергәннәр. Һәм ул гадәттә өлгергән башаклар һәм иген басуы төсендәге алтын-сары толымлы, "Сөмбел" чәчле кыз кыяфәтендә күзалланган. Халык "Сөмбелә" бәйрәмен аеруча көр күңел белән үткәрә торган булган. Һәр өйдә бу көнгә яңа уңыштан төрле камыр ашлары әзерләнгән, йола ризыгы һәм муллык билгесе булган бавырсак пешерелгән.

**1 бала**:
Көз килде, уңыш булды,
Табын сый белән тулды.
Рәхим итегез, дуслар,
Көзге бәйрәмгә!



**2 бала.**
Урман кырларга
Килде матур көз
Җәй үтте диеп
Үкенмибез без.
**3 бала.**
Көзге урман тып-тын булган
Агач башы-ялангач,
Соңгы яфрак төшә калтырап,
Әз генә җил шаяргач.
**4 бала.**
Уңыш җыелды.
Аккошлар китте.
Матур көз ае
Октябрь җитте.
**5 бала.**
Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.

Китә башлады бездән кошлар.
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.
**6 бала.**
Ашлык булып җирдә үсә
Уңыш бит ул сөмбелә.
Бөтен җирне нурга күмә,
Кояш бит ул Сөмбелә.
**Тәрбияче:** Балалар, бәйрәмебезгә Сөмбеләне чакырыйк инде.
**Балалар:** Сөмбелә! Сөмбелә!
(Матур көйгә Сөмбелә керә)
Саумы, якын дусларым!
Сезне сагынып килдем мин.
Сезгә аяз көннәр дә,
Байлык та китердем мин.
Мин көз кызы-Сөмбелә,
Көзге байлык кулымда.
Чакырам мин һәммәгезне
Шушы бәйрәм түренә.
**Тәрбияче:** Балалар, әйдәгез сорыйк әле, Сөмбелә безгә нәрсәләр алып килде икән? (Балалар җитәкләшеп түгәрәк ясыйлар)
**“Көз, көз, әйт әле” җыры**
**Сөмбелә:**
Балалар, әйдәгез, табышмак уены уйнап алабыз. (Балалар табышмак әйтәләр)
1.Тәрәзәсе юк, ишеге юк, эче тулы халык. (кыяр)
2.Өсте яшел, асты кызыл, җирдә үсә. (кишер)
3. Кат-кат тунлы, карпы буйлы. (кәбестә)
4. Җир астында җиз бүкән
Ул ни икән (бәрәңге)
5.Үскәндә яфрагын ашыйлар,
Үсеп җиткәч үзен ашыйлар. (суган)
6.Җир астында кызыл әтәч. (чөгендер)
**Сөмбелә:**
Табышмаклар күп беләсез, зирәк икән үзегез.
Бәхетле һәм матур булсын сезнең һәрбер көнегез.



Ай-хай! Быел уңыш бигрәк мул булды.Ул кишер, помидор, чөгендер.Үзләре шундый эре! Күрдегезме, уңышларым шундый күп! Әйдәгез, уйнап алабыз.
**Уен: “Кем тизрәк җыя”**
**Сөмбелә:** Дусларым, күрәм, сез бик җитезләр икәнсез.
**Тәрбияче:** Дуслар, бәйрәмгә килгәнсез,

Гөлдәй матур киенгәнсез.
Бик матур җыр өйрәндегез
Җырлап бирегез безгә!

**“Дождик-озорник” җыры**

**Сөмбелә:** Кадерле дусларым, мин сезгә бик матур яфраклар алып килдем. Ә хәзер, әйдәгез, яфраклар белән уйнап алыйк.Сез мин күрсәткән яфракларның кайсы агачтан коелганын әйтерсез.

**“Яфрак тану” уены**

**“Яфракларны тизрәк җыябыз”** уены (балалар өрәңге, каен, имән яфракларын җыеп аерым төркемнәргә басалар)

**Сөмбелә:** Булдырдыгыз, балалар, барыгызга да зур рәхмәт! Һәрвакыт шундый белемле, зирәк, тырыш, уңган булыгыз.

**Җыр” Яфрак бәйрәме”**

**Сөмбелә:** Минем дә сезгә бүләк-табышмакларым бар. Яле, тыңлап карагыз:
Кар астында кыш үткәрә,
Ямь-яшел тунын киеп.
Көздән чәчеп калдырганга
Өлгерә ул иң элек.
**Балалар:Арыш**
Сөмбелә: Буеның озынлыгы белән
Аз калыша арыштан.
Ул аңардан күп уздыра
Уңыш өчен ярышта.
Эшкәртсәләр бөртегенең
Бөтен шартын китереп
Онынннан күмәч пешә
Күбек кебек күпереп.
**Балалар: Бодай.**
**Сөмбелә:** Бик дөрес, дусларым, зирәклегегез мине сокландырды.
**7 бала:** Ипи басуда үсә
Аннан амбарга күчә.
Аннары мичтә пешә
Кызарып мичтән төшә.
Шуннан килә өстәлгә
Безгә куәт өстәргә.
Ипи булса табында
Булдырам мин барын да.
**8 бала:** Көзнең иң олы бүләге
Икмәк тора табында

Тормышыбыз ямьле булыр
Икмәк булган чагында.
Сөмбелә: Яшәү чыганагы-кояш нурын
Җир җылысын саклап үзендә
Күкрәкләргә терәп кисәр икмәк
Һәр табынның тора түрендә.

**(Сөмбелә тәрбиячегә ипи бирә)**

**Тәрбияче:** халык мәкале болай ди: Пешкән икмәкнең исе-һәр чәчәктән хуш исле. Ипи - тормышның нигезе. Аны хөрмәт итәргә, валчыгын да идәнгә төшермәскә кирәк.Уңыш басуларда гына түгел, бакчаларда да бик уңган.Без яшелчәләр турында бик матур җырлы-уен беләбез.

**Җырлы-биюле уен “Бар матур бакча”**

**Сөмбелә:** Бигрәк матур җырладыгыз, биедегез,
Уйнадыгыз, шигырьләр сөйләдегез.
Барысы өчен рәхмәт сезгә.
Алдагы көннәрдә дә
Телим сезгә уңышлар.
Муллыкта, рәхәт тормышта
Яшәгез, нәни дуслар! Сау булыгыз!
Тәрбияче: Сау бул, Сөмбелә!
Балалар, сезгә бәйрәм ошадымы?
Барыгыз га да бик зур рәхмәт.
Бүгенгә без хушлашабыз,
Бәйрәмебезне җыр белән төгәллибез.



**Җыр “Сөмбелә”**

**Сценарийдәге җырларның авторлары:**
**“Көз-көз әйт әле” - Г.Гәрәева сүзләре һәм көе**
**“Дождик-озорник” - З.Роот сүзләре һәм көе**
**“Яфрак бәйрәме” - Л.Лерон сүзләре, Р.Еникеев көе**
**“Бар матур бакча” - халык сүзләре, А.Шакиров көе**
**“Сөмбелә” - Г.Зәйнәшева сүзләре, М.Шәмсетдинов көе**

**“Ак чәчәк таҗы”**

Әзерләделәр: Шәйдуллина Л.Р., Гарипова Г.Ф.

Кереш.

Һәр халыкның үз гореф-гадәтләре, йолалары, уеннары була. Татар халык уеннары балаларны тәрбияләүдә бик зур чара булып тора, аларны борынгы заманнардан ук кулланганнар. Шул уеннар ярдәмендә балалар күңелендә туган теленә, жиренә, халкына мәхәббәт, өлкәннәргә мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләнә. Милләтебезнең гореф-гадәтләре, тормыш-көнкуреше чагылыш тапкан татар халык уеннары балаларны кешелекле, шәфкатьле булырга өйрәтә.Әлеге уеннарны уйнап үскән балалар киләчәк буыннарга да ана телен саклап калырга, милли хәзинәбезне онытмыйча, гомер буена үз милләтенә тугъры калырга ярдәм итәр дип ышанабыз.

“Ак чәчәк таҗы” дигән уен-викторина

Уенның максаты:

Сөйләм телен үстерү. Гаилә кыйммәтләре белән тирәнтен таныштыру, балаларда үз гаиләң белән горурлану хисе тәрбияләү.

Бурычлар: Гаилә дигән сүзнең мәгънәсенә төшенү. Олыларга игътибар хисе тәрбияләү.

Әзерлек эше: бәйрәмнәр турында әңгәмә алып бару, гаилә турында шигырьләр, җырлар өйрәнү.

Җиһазлар: Катыргыдан ясалган акчәчәк таҗы, тажда төрле биремнәр язылган, балаларның гаилә әгъзалары белән төшкән фотолары.

Уенның барышы:

Тәрбияче акчәчәк таҗын күрсәтә һәм үз янына уенга чираттан төрле гаиләне чакыра .

Эшчәнлек барышы:

Кереш өлеш.

Тәрбияче: Хәерле кич хөрмәтле әти-әниләр һәм балалар!

Тәрбияче: Кәефләрегез ничек?

Тәрбияче: Ясап куйдым бер чәчәк,
Сигез таҗлы ак чәчәк
Һәр таҗыннан яхшылык
Һәркем табып алачак.
Берсе аның мәрхәмәт,
Икенчесе-мәхәббәт,
Өченчесе- тыйнаклык,
Дүртенчесе-җыйнаклык,
Бишенчесе-ихласлык,
Алтынчысы-гаделлек,

Җиденчесе-тугрылык,
Сигезенче-гадилек.
Кайсы кирәк, ал, дустым,
Мин тагын да ясармын.
Сигез таҗлы чәчәккә
Яхшы сүзләр язармын

Тәрбияче: Хөрмәтле әти-әниләр, балалар, мин сезне бүген “Ак чәчәк таҗы” дигән уен-викторина уйнарга чакырам. Ни өчен ак чәчәк таҗы дип атала соң бу уен? Чөнки аның һәрбер таҗында биремнәр бар. Нинди биремнәр икәнен беләсегез киләме?
Кадерле әти-әниләр!
Бергәләшеп без басыйк
Матур түгәрәк ясыйк
Берәр санамыш әйтеп
Уеныбызны башлыйк.
Әке бәке кыек сәке, эремчек. Син калып тор, ә син чык.
Уеныбызны башлаганчы сезне гаилә кыйммәтләре һәм гаилә традицияләре белән таныштырып китәсем килә.
Җирдә миңа ни кирәк?
Әти дә әни кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәгән өй кирәк!
Әти дә әни кирәк!
Без яшәгән өй кирәк!
Гаилә! Ә нәрсә соң ул гаилә? Ул нәрсәдән башлана?
Әти-әниләр, балалар: Гаилә ул туган йорт һәм якын кешеләр.
Тәрбияче: Әйе, бик дөрес. Гаилә ул уртак куанычлар, уртак мәшәкатьләр, мәхәббәт һәм бәхет. Гаилә ул кеше өчен иң кыйммәтле, иң кирәкле, һәрбер кешенең үз гаиләсе була. Бездә сезнең белән балалар бакчасында көн саен очрашабыз, димәк бездә бер зур, дус гаилә. Ә сезнең гаиләгездә кемнәр яши?
Балалар: Әби, бабай, әти, әни, энем, сеңлем, абый, апай.
Сезнең якын туганнарыгыз, туган йортыгыз булганга мин бик шат, чөнки сезне анда яраталар, көтәләр, сезнең турында кайгырталар. Өйдәгеләрегезне хөрмәт итегез, игътибарлы булыгыз.
Ә хәзер әйдәгез уеныбызны башлыйк.
Сезгә хәзер акчәчәкнең таҗын өзеп, андагы биремне укып, сорауларга җавап бирергә кирәк була .
**1“Мәкальләр әйтү” уены.**
Уенның уйнау тәртибе:

Әти-әниләр , балалар белән гаилә темасына багышланган мәкальләр укып аның мәгънәсен аңлатып китәргә кирәк булачак.

1. Тату гаиләдә җаның ял итә.
2. Мәхәббәтсез гаилә - тамырсыз агач кебек.
3. Туганнар татулыгы байлыктан күп артык.
4. Ата-бабалы кеше - тамырлы имән.
5. Кош канаты белән, гаилә татулыгы белән көчле.
6. Балалы кеше - бай кеше.
7. Әткәй - шикәр, әнкәй – бал.
8. Бердәм өйдә бәрәкәт була.

**2 "Гаилә кыйммәтләрен атау" сүзне әйтеп бетер уены**



**Гаилә ул-............**

Гаилә ул - мәхәббәт
Гаилә ул - шатлык
Гаилә ул - изгелек һәм мәрхәмәтлек
Гаилә ул - бер-береңне аңлау һәм ышаныч
Гаилә ул - тугрылык
Гаилә ул - хөрмәт
Гаилә ул - балалар.

**3 "Милли ашлар" уены**

Татар халкы элек-электән аш-су әзерләргә оста булган. Ә сез нинди татар халык ашларын беләсез? Әйдәгез бергәләп милли ризыкларны атап китик әле.

(Кыстыбый, өчпочмак,чәк-чәк, калҗа, гөбәдия)

Өсте такта, асты такта, уртасында боламык (Кыстыбый)

Эче өрелгән, якасы бөрелгән, сырлы кәләпүш кигән, табын түренә менгән (Бәлеш)

Тап табышмак: табага ябышмак (Коймак)

Үзе түгәрәк, урыны түрдәрәк, эче тулы күзәнәк, бар нәрсәдән кадерлерәк (Икмәк)

**4 "Ягымлы сүзләр әйт"уены**

Уйнау тәртибе
Балалар әти-әниләренә җылы, тәмле сүзләр әйтергә тиешләр.
Мәсәлән:

| | |
|---|---|
| Әнием- .......... | Әтием-........... |
| Әнием - бәгърем | Әтием - яклаучым |
| Әнием- күз нурым | Әтием - саклаучым |
| Әнием - матурым | Әтием - кояшым |
| Әнием - бердәнберем | Әтием - мәхәббәтем |

**5 " Булсаң зирәк - әйт тизрәк"**

Ә хәзер бергәләшеп "Һәрвакыт булсын кояш "дигән җырны җырлыйк.

**“Авыл өендә кунакта”**

Әзерләделәр: Сабирова А.М. Хөснетдинова Р.Ә.

**Авыл өендә кунакта.**

**(Зурлар төркеме өчен)**

**Максат:** Балаларны татар халкының көнкүреш һәм гореф-гадәтләре, йолалары, уеннары белән тирәнтен таныштыру, сабыйларның зәвыгын үстерү, халкыбызның рухи байлыгына ихтирам, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Китап күргәзмәсе “ Халкыбызның күңел бизәкләре”, сандык һәм сандык эчендә – чиккән сөлгеләр, ашъяулык, калфак, түбәтәйләр, күлмәк, җәймә, кулъяулык, чулпылар, шәл, читек.

**Катнашалар:**

**Алып баручы:** Балалар, әйдәгез бүген без сезнең белән күрше авылда яшәүче Гөлсу әбинең хәлен белергә барабыз.*(Әбинең йорты янына барып җитәләр, ишек шакыйлар),*

**Әби чыга:**

-Һай, балакайларым, күрми дә торам икән бит. Әйдүк, әйдүк, түрдән узыгыз! Җиңел аякларыгыз белән! Исән- сау гына килеп җиттегезме, алтын бөртекләрем, хөрмә җимешләрем!

**Балалар:**

Исәнме, әбекәй!



**Әби:**

-Бик исән, балакайларым, бик исән! Рәхмәт килүегезгә! Әйдәгез әле, йортка дога кылып алыйк. Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Илгә - көнгә тынычлык, йортларга иминлек, барыбызга да тазалык бирсен ходай! Әмин!

**Рания:** *( сандыкка күрсәтә)*

Серле сандык, матур сандык
Кызыктыра мине күптәннән,
Әйдә, карыйк, ниләр калган икән?
Истәлеккә безгә үткәннән.



**Әби:**

- Үз эчендә бик күп серләрне саклаган сандык бу, кызым. Әйдәгез, балалар, уңайлырак итеп утырыгыз. Мин сезгә хәзер

сандыгымның серләрен ачам.(Әби сандыкны ачып, аннан сөлге чыгара.) Балалар, беләсезме бу нәрсә? Бу - сөлге. Сөлге – татар хатын-кызының уңганлыгына, осталыгына һәйкәл. Кеше тормышындагы бер генә вакыйга да сөлгедән башка узмый. Бала тугач аны ак сөлге белән төргәннәр, кыңгыраулар тагылган туй атларын сөлге белән бизәгәннәр, киленнең каенанасына биргән иң беренче бүләге дә сөлге булган. Аның өчен ир- егетләр сабан туйларында бил алышканнар, малайлар аргамакларда чабышканнар. Кунакларны да ипи-тоз куелган сөлге белән каршы алганнар. Ә менә монысы нәрсә? (Сандыктан калфак чыгара.) Әйе, бу калфак, сабыйларым. Ул татар хатын-кызларының борынгы баш киеме. Аны энҗе-мәрҗәннәр, сәйләннәр белән чиккәннәр. (Кулына түбәтәй ала.) Ә менә бу әйберне кем белә, балалар? Әйе, дөрес әйтәсез. Түбәтәй – борынгыдан алып бүгенге көнгәчә ир-атларның яратып кия торган баш киеме.

**Алып баручы:**

- Әби, безнең Рәхим “Түбәтәй” шигырен сөйләп китсен әле.

**Рәхим:**

Әнием туган көнемә
Бүләк итте түбәтәй,
Шундый матур түбәтәем
Үзем кебек бәләкәй.

**Әби:**

- Рәхмәт, балалар. Ә менә хәзер әйтегез инде сез миңа, бу нәрсә икән?

**Балалар:**

- Алъяпкыч .

**Әби:**

- Әйе, балалар. Алъяпкычны кием пычранмасын өчен ябып йөриләр. Аны да матур җепләр белән бизәкләп чиккәннәр.

**Алып баручы:**

- Ә Сәфинә алъяпкыч турында шигырь белә.

**Сәфинә:**

Алъяпкычымның бизәге
Әллә кайдан күренә,
Матур ләла чәчәк төшкән
Бик ошады үземә.

**Әби:**

-Рәхмәт, кызым.Чыннан да, алъяпкычың бик матур. Балалар, менә бу зур сандыгым эчендә , кечкенә сандыгым да бар әле минем. *(Әби чулпы, беләзек, алкалар, муенсалар күрсәтеп сөйли)*. Чулпы, беләзек, алкалар - татар кызларының иң яраткан бизәнү әйберләре.

- И, балалар, картлык-шатлык түгел шул ул. Кунакларны сүз белән генә сыйлап , чәй куярга да онытып торам икән. Самавырымны гөрләтеп җибәрим әле.

**Алып баручы:**

- Әби, самавыр кайнаган арада без сиңа җырлап күрсәтәбез.
- *(“Күңелле сәяхәт” җыры)*

**Әби:**

- Әйдәгез, балалар, чәем кайнады. Табынга рәхим итегез!

*(Чәй эчү күренеше)*

**Алып баручы:**

- Әби, коймагың бигрәк тәмле булган.
- **Адилә:**

Коймагы да, коймагы
Агып тора каймагы,
Табада пешеп тора
Табынга төшеп тора.
“Кайнар”! Яланкул тотма!
Тәмле, телеңне йотма!
Син телеңне йотсаң, Сәфинә
Кем рәхмәт әйтер әбигә?



**Әби:**

-Бик рәхмәт, балакаем!
Балалар, әйдәгез сезнең белән бер уен уйнап алабыз.

*(“Йөзек салыш” уены уйнатыла)*

Уйнаучылар түгәрәкләнеп утыралар. Бер балада йөзек була. Шул бала түгәрәк буенча кулларына йөзек салган кебек әйләнеп чыга. Сиздермичә генә бер балага йөзекне сала, үзе уртага баса һәм: “ Кемдә йөзек йөгереп чык!” -ди. Йөзеге булган бала уртага чыгарга тиеш, ә калганнар аны тотып алырга тырышалар. Тотсалар, аңа җәза бирәләр. Һәм ул, җәзаны үтәгәч, беренче бала кебек, йөзек сала башлый. Уен дәвам итә.

**Алып баручы:**

- Әбекәй, бик зур рәхмәт сиңа, синдә кунак булдык. Безгә балалар бакчасына кайтырга вакыт. Ләкин кайтканчы сиңа, үзебезнең яраткан җырыбызны башкарасыбыз килә. *(“Әбием, әбекәем” җыры башкарыла).*

**Әби:**

- Бик зур рәхмәт сезгә, балакайларым. Бик булдыклы балалар икәнсез. Исән-сау булыгыз, авырмагыз, өйдә эти- әниләрегезне, әби-бабаларыгызны, балалар бакчасында тәрбиячеләрегезне тыңлагыз, тагын шулай кунакка килегез. Сау булыгыз, балакайларым.

**Алып баручы:**

- Сау бул, әбекәй.

**“Бала туды - шатлык артты”**
**(Исем кушу йоласы)**
(Зурлар төркеме өчен)

Әзерләделәр: Хабибуллина Э.Ю., Газизуллина К.И.

**Кереш:**

Халкыбызның рухи мәдәниятенә алып керүче тагын бер чыганак- татар халкының милли, күркәм йолалары. Милли йолалар, гореф гадәтләр аша, балалар халкыбызның элеккеге тормышы, яшәү рәвеше белән танышалар.
Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга милли тәрбия бирү һәм әхлак сыйфатлары тәрбияләүдә халкыбызның гореф-гадәтләрен истә тотып үткәрелгән чараларның роле бик зур. Без үзебезнең “ Бала туды - шатлык артты” дигән милли чарабызны туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышладык. Балаларны исем кушу йоласы белән таныштырдык.
Шушы күркәм милли йола аша элеккедән бүгенгә кадәр килгән һәм киләсе буынны дәвам итсеннәр иде, дигән максат белән үткәрелде. Хәзерге буын балалары милли хәзинәбезне, ана телен саклап калсыннар иде.
**Катнашалар:** Әти, әни, дәу әни, кыз, кызның сеңлесе, бишектәге бәби, кызның дус кызлары, мулла.
**Җиһазлар :** Өй күренеше, алан күренеше.
**Максат:** Халкыбызның гореф гадәтләренә, йолаларына хөрмәт тәрбияләү.
**Бурычлар:**
1. Исем кушу кеше гомерендәге иң әһәмиятле мизгел һәм тәүге зур бәйрәм икәнлеген анлату.
2. Исем кушу һәр халыкның милли традицияләре белән бәйле булганлыгын күрсәтү.
3. Исем кушуның җаваплылыгын аңлату. (Мәгънәле дә милли дә булсын, исем - кешенең гомерлек юлдашы).

Кичәнең барышы:

(Алан күренеше, жәйге көн. Талгын көй яңгырый, ишек алдына кыз бала йөгереп чыга)
**Сәфинә:** Кызлар, әйдәгез уйныйбыз, килегез тизрәк. Рания, Азалия, Мәликә, буген шундый матур көн.
(Кызлар йөгереп чыгалар, шатланып сикерешәләр)
**Сәфинә:** Кызлар, минем зур шатлыгым бар.
**Азалия:** Сиңа матур күлмәк алдылармы әллә?
**Сәфинә:** Юк
**Рания:** Сиңа зур курчак алдылармы ?
**Сәфинә:** Юк

**Зәринә:** Белдем, белдем, сиңа яңа китап  алганнар инде…
**Сәфинә:** Юк. Минем  зур шатлыгым - сеңелем туды. Безнең өйгә бәби кайтты.
(Кызлар шатланышып сикерешәләр)
**Кызлар:** Ә исеме ничек?
**Сәфинә:** Әле исем кушмадык, буген безгә кунакка килегез, исемен бергәләп сайларбыз.
**Кызлар:** Киләбез, киләбез.
(Өй күренеше, талгын гына көй яңгырый. Яшь ана бишек янына чыгып утыра, бишеген тирбәтә)
**Алып баручы**: Бала туды буген җиргә,
Фәрештәләр аңа юл ачты.
Күкләр иле изге җаннан булган
Бер баласын җиргә озатты.
Гаиләгә шатлык булып, өмет һәм куанычлар өстәп, бала туды. Ул, үзенә бәхет даулап, тәүге авазын салды.  Ана, сабыена иң иркә сүзләр әйтеп, ак биләүгә биләп, тал бишеккә салып, бишек җырын сузды.
(Яшь әни бишек җырын башкара)
**Әни:**  Аллаху, аллаху.
Кәҗәләрне талга ку.
Кәҗә талны ашасын,
Бәби йоклый башласын.



**Әни:** Бәхетле бул, балам, сәламәт бул, балам, тәүфыйклы бул балам.
(Баланы бишеккә сала, кызлар килеп керәләр)
**Әни:** Исәнмесез ,кунаклар, түрдән узыгыз әйдә.
Куңел ачып сыйланыгыз. Сыйларыбыз өстәлдә.
**Азалия:** Исәнмесез, саумысез.
Бәби күрергә килдек без, нигә каршы алмыйсыз?
**Рания:**   Күчтәнәчне, кызганмадык
Алып килдек мул итеп,
**Зәринә:** Бәбине күрсәтегез инде
Карарбыз матур диеп.
**Дәү әни:** Күз тимәскә миләш тегеп.
Беләзек бүләк итәм мин.
Сау сәламәт бала булып
Үскәнен дә көтәрмен.
**Сәфинә**: Сеңелебезгә исем кушабыз бүген, ләкин әле исем сайламадык, бик матур исем кирәк булыр инде кечкенә бәбиебезгә. Кызлар, әйдәгез, исем сайлыйбыз.
(Кызлар тугәрәккә басалар, Сәфинә санамыш әйтә)
Карга, чыпчык, син кал, син чык.

(Уртага бер бала сикереп чыга, уйланып торганнан соң)
**Азалия:** Айтуган.
**Рания:** Кит әле, безнең бала малай түгел бит.
**Сәфинә:** Әйдәгез тагын. Карга чыпчык, син кал, син чык.
**Зәринә:** Мин таптым, мин таптым, Хәят булсын .
**Әни:** Минем Хәят исемле кызым бар инде.
(Өйгә утын күтәреп, әти кеше килеп керә, мич алдына китереп сала, кулларын кага)
**Әти:** Әйдәгез Айсылу дип кушабыз,  Айсылу бик матур исем, берсе Ай, берсе Сылу. Кызым , сиңа ошыймы Айсылу исеме.
**Сәфинә:** Әйе, әтием бик ошый.
**Әни:** (Кечкенә кызын кочаклап, ) Кызым, сина да ошыймы?
**Хәят:** Ошый.
**Әти:**  Айсылу булсын.
(Шулвакыт бала елаган тавыш ишетелә, әти белән әни, тс-тс-тс, бала елый дип кызларны  тынычландыралар, әни баласы янына китә.
**Зәринә:** Әнвәр абый, шушы булдымы инде балага исем кушу йоласы?
**Әти:** Балага исемне мулла куша, ул дога укый, азан әйтә, аннан соң исемне баланың колагына кычкыра.
**Әни:** Балалар, килегез, тәмле күмәч белән сыйланыгыз.
(Бүлмәгә мулла абзый керә)

( Мулла баланың баш очына килеп, дога укып, колагына укып, исем куша).
**Әни:** Ә хәзер, кунаклар, барыгызны да бәби ашына чакырам. Әйдәгез, рәхим итегез.
**Алып баручы**: Татар халкы элек-электән кунакчыл булган.Татар халкының йолаларын, гореф гадәтләрен онытмасак иде.

# “ ЧӘЙ ЭЧӘБЕЗ БАЛ БЕЛӘН”

Әти-әниләр белән үткәрелгән күңел ачу чарасы

Әзерләделәр: Шандарова Г.Р., Хабибуллина А.М.

Максат: балаларны борынгыдан килгән чәй эчү традициясе, чәй пешерүнең милли ысуллары белән таныштыру; чәй эчү йоласының әдәби әсәрләрдә чагылышын күзәтү; чәйнең сәламәтлеккә уңай йогынтысын, файдасын төшендерү.

Җиһазлау: самавыр, чәйнек, чәй ашлары, савыт-саба һәм башка кирәк-яраклар.

Чәй эчәбез бал белән.
Бала-чагалар белән.
Бала –чага алты җан:
Әхмәт, Нәҗип, Закирҗан,
Зәйнәп белән Галия,
Иң нәние Асия.



Тәрбияче: Кадерле әти-әниләр, кунаклар һәм балалар! Без бүген сезнең белән чәй бәйрәменә җыелдык. Әйдәгез әле, бергәләп уеннар уйнап, аннан чәй табыны әзерләп, җыелып чәй эчеп алыйк.

Җир шарында иң киң таралган эчемлек - чәй. Хәзерге көндә чәй эчеп карамаган кешене очратып булыр микән? Аны дөньяның төрле почмакларында эчәләр. Ләкин халыкның бик азы гына чәйне дөрес итеп эчә белә, дисәк тә ялгыш булмас. Чәйне күпләрегез дөрес эчәме? Чәйнең безгә нинди файда китерүен беләсезме? Бүген шул хакта сөйләшербез.

Әйтегез әле, чәй әзерләү өчен иң беренче чиратта нәрсәләр кирәк?

Балалар: Чәйнек, су.

Тәрбияче: Ә тәмле чәй әзерләү өчен?

Балалар: Самавыр, чишмә суы.

Тәрбияче: Элек чәйне самавырларда гына кайнатканнар, ә су кайнату өчен утлы күмер яки нарат күркәләре кулланганнар. Без бүген элекке традицияләрне кире кайтарырбыз.

Балалар, мин сезгә иң элек чәй эчүнең бер тарихын сөйләп үтәсем килә.

Моннан бик күп гасырлар элек, Кытай императорына эчү өчен су кайнатканнар. Савытларына чәй куагыннан берничә яфрак төшкән һәм суның төсе караңгыланган. Аннан бик тәмле хуш ис килгәнен тоеп алганнар. Эчеп карагач, шаккатканнар. Бу дөньяда иң беренче чәй эчү булган.

Шулай итеп, иң беренче чәй эчү тантанасы Кытайда барлыкка килгән. Соңрак дөньяның күпчелек илләрендә чәй иң яраткан эчемлеккә әверелә.

Чәй кайда үстерелсә, ул шул ил, республика исеме белән йөртелә. Әйтик, һинд чәе, грузин чәе.

Тәрбияче: Самавырыбыз кайнап чыкканчы “Без, без идек” уенын искә төшереп алыйк.

Без, без, без идек.
Без унике кыз идек;
Базга төштек, бал ашадык,
Келәткә кердек, май ашадык;
Өйгә мендек, өйрә эчтек,
Коега төштек, су эчтек;
Бер тактага тезелдек,
Таң атканчы юк булдык,
Авыгыңны яп та йом!
(Көлгән уенчыга җәза бирелә)

Тәрбияче: Самавырыбыз кайнап та чыкты, әйдәгез чәй пешерү серләрен өйрәник. Ягез, әниләр, кайсыгыз безне чәй пешерергә өйрәтә.

Беренче әни. Чәй пешергәнче, чәйнекне ике мәртәбә кайнар су белән чайкатып алырга кирәк. Аннары корытып сөртергә. Чәйне өч кашык салырга. Чәй пешерә торган суны беркайчан да артык кайнатып чыгармыйлар. Самавыр өч төрле сигнал бирә. Башта җырлый, аннары шаулый, аннары быгырдап кайный. Чәй пешерү өчен чишмә суы кулланылса, яхшы була. Су бары тик бер тапкыр кайнаган булырга тиеш. Өстәп кайнаткан, җылыткан сулар чәйнең сыйфатын боза. Чәй пешергәндә, чәйнекне җитен сөлге белән томалап торалар. Менә шундый чәй генә тәмле, файдалы, хуш исле, дөрес пешерелгән була.

Икенче әни: Бездә кара чәй эчү гадәткә кергән. Тагын яшел, кызыл чәйләр дә була. Бу төрле төстәге чәйләр барысы да бер үк чәй куагыннан алына, ә төсләре исә чәй яфрагын эшкәртү ысулыннан тора.

Тәрбияче: Балалар, ә сез чәйне нәрсә белән эчәсез?

Балалар: Бал, шикәр, кайнатма, кәнфит, җимеш, лимон, как.

Өченче әни:Чәйгә сөт салып, бал белән эчү - иң файдалысы. Болай эшләгәндә катлаулы сөт ризыгы җиңелрәк эшкәртелә. Ә чәйдә була торган кофеин кебек матдәләрне сөт тизрәк эшкәртә. Шулай итеп чәй сөткә, сөт чәйгә ярдәм итә.

Тәрбияче: Ә татар халкы элек-электән чәйне җиләк-җимештән, яшелчә һәм аларның яфракларыннан, үләннәрдән әзерләп эчкән. Шуңа күрә дә аларны халык

шифалы чәй  дип атый. Дару үсемлекләреннән әзерләгән дәвалы  чәйләрне  дә эчеп караганыгыз бардыр. Хәзер шуларны искә төшереп алыйк.



Бер уен уйнарга тәкъдим итәм. Биредә дүрт чәйнек. Аларга дүрт төрле шифалы чәй салынган. Дегустация үтәргә берәр уенчы чыга һәм чәйләрнең һәрберсен эчеп карап, аның нинди чәй икәнен билгеләргә тиеш (карлыган, юкә яфрагы, лимон, кура җиләге, җимеш, мәтрүшкә салып пешерелгән чәйләр).

Тәрбияче: Әниләребез шундый тәмле ризыклар пешереп килгәннәр. Нинди ризыклар икәнен  алар табышмак итеп әйтер.

1. Юка, юка эчендә ботка. (Кыстыбый)

2. Уч төбе хәтле камыр, эчендә ит, суган, бәрәңге, кайсыгыз исемен әйтер? (Өчпочмак)

3. Таралып тора дөгесе, йөземе майда йөзә, тәмле корт та, йомырка да була аның эчендә (Гөбәдия)

4. Әзләп, әзләп камыр алам, табадагы майга салам, озак тормый, бик тиз пешә тәлинкәгә килеп төшә.(Коймак)

5. Тәлинкәгә камыр бастым, ваклап майда кыздырдым. Таралып китмәсен диеп, бал белән ябыштырдым.(Чәк-чәк)

6. Камыр җәйдем нәзек итеп, өчпочмаклап кисеп чыктым. Кайнар майга салып алдым. Әйтегез, ни килеп чыкты? (Кош теле)

Тәрбияче: Самавыр  кайнады, чәй пешерергән, өстәл әзер. Әйтегез эле, нинди чәй иң тәмлесе була?

Әниләр бергә: Бергәләп эчкән чәй.

Тәрбияче: Барыгызны да чәй өстәленә чакырам. Рәхим итегез! Чәегез тәмле булсын! Бу күңелле мизгелләрне истә калдырыгыз. “Бер чынаяк чәйнең кырык ел хәтере бар”,- диләр бит.

## “Җеп эрлибез бергәләп”

Әзерләделәр:Сиразетдинова Л.Р., Гатауллина Г.Ф.

## Кереш

Һәр халыкның үз гореф-гадәтләре, йолалары була. Татар халкында да алар бик күп. Без үзебезнең “Җеп эрлибез бергәләп” дигән музыкаль театраль сценарийбызны әзерләдек. Балаларны татар халкының гореф –гадәтләре, йолалары белән таныштырасыбыз килде.

Татар халкының милли бәйрәмнәре балаларга тәрбия бирүдә бик зур чара булып тора, алар борынгы заманнарда да булган. Шул йолалар ярдәмендә балалар күңелендә туган теленә, жиренә, халкына мәхәббәт, өлкәннәргә мәрхәмәтлелек хисләре тәрбияләнә. Милләтебезнең гореф-гадәтләре, тормыш-көнкуреше балаларны кешелекле, шәфкатьле булырга өйрәтә.

Әлеге йолаларны күреп үскән балалар киләчәк буыннарга да ана телен саклап калырга, милли хәзинәбезне онытмыйча, гомер буена үз милләтенә тугъры калырга ярдәм итәр дип ышанабыз.

## “Җеп эрлибез бергәләп”.

**Максат:** Онытылып барган татар йолалары аша хезмәт сөючәнлек тәрбияләү, тормышта һөнәрнең мөһим икәнлеген аңлату.

**Бурычлар:**

1.Татар халык йолаларының, гореф-гадәтләренең әһәмиятен балалар күңеленә төшендерү.

2.Балаларның иҗади активлыгын камилләштерү һәм бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

3.Эстетик тәрбия бирү, татар милли сәнгатенә мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

**Җиһазлау:** Авыл өе, түрдә мич, ипи көрәге, сәке, анда чигелгән мендәрләр, йон кабасы, орчык, сандык, өстәлдә самавыр тора.

Сәке янында үз үзе белән сөйләшеп ана йон эрләп утыра.

**Әни**: - Эх, бар иде бит безнең дә яшь чаклар! Өмә ясап җеп эрли идек, анда егетләр-кызлар була иде. Уен-көлке, җыр-бию, такмаклар әйтешә идек. Өйгә кыз килеп керә.



**Айзиля:** Нишләп үз–үзең белән сөйләшеп утырасын, әнием?

**Әни**: Әй кызым, яшь чакларны искә алып утырам әле.

**Амалия**: Әнием, сезне алма апалар кунакка чакырды, барасызмы?

**Әни:** Чакырган җиргә барабыз, кызым, барабыз.

**Амалия:** Сез кунакка киткәч, кызлар белән җеп эрләү өмәсе ясап алыр идек...

**Әни:** Бик әйбәт булыр, кызым. Бергә-бергә эшләгәндә, эш тә тиз эшләнә. Хәзер әтиеңә генә әйтим дә...
**Амалия**: Кызларга әйтергә барам,
Барысы да килсеннәр.
Бездә аулак өй икәнен
Егетләр дә белсеннәр.
**Азалия:** Йон тетәрбез, җеп эрләрбез,
Кайсыбыз камыр изәр. Егетләрне дә чакырыйк.
Гармунда уйнар Хәлил.
Кыз чыгып китә. Залның бер почмагында кызлар тора. Кыз аларның янына килә.
**Амалия:** Кызлар, килегез безгә,
Орчык бәйрәме ясыйк.
Егетләр килә башласа
Барыбыз бергә качыйк.
**Элина:** Кызлар: Әйдәгез, барабыз! Барабыз!



**Айзиля:** Рәхмәт инде,дускаем,
Безне чакырган өчен.
Көне буе ял иттем,
Юкка китмәстер көчем.

**Амалия:** Өмә ясыйк әле бүген,
Әтиләр өйдә юкта.
Кызлар исемлеген төзик,
Санап куйыйк орчык та.
(Бергәләп җыелгач, күмәк эш башлана: кемдер йон яза, кемдер йомгак чорный, кемдер бәйли)
(Гармун уйнап егетләр килә).
**Талия**: Егетләр килә! Качабыз.
**Сәидә:** Эзләсеннәр әле безне,
Бар җирдән карасыннар.
Безнең санны белер өчен
Орчыклар санасыннар.
Кызлар качалар. Егетләр керә.
Егетләр: Исәнмесез, кызлар! Кая соң үзләре?
**Рамир**: Орчыклары монда,үзләре дә ерак түгелдер. Орчыкларын саныйк әле, ничә кыз бар икән?
**Әмир**: Берәү, икәү, өчәү, дүртәү,
Барысы бергә сигез.
**Шамиль**: Эрләгән йомгакларының
Зурлыклары бертигез.
**Хәлил:** Кызлар, чыгыгыз инде! ( Кызлар чыгалар.)
**Рамир:** Җепләр эрлисез икән,

Эшләрегез уң булсын.
Оекбаш, бияләй белән
Мич башларыгыз тулсын.
**Талия:** Ярышып җепләр эрләдек,
Бөтерелде орчыклар.
Алып килгән йоннар бетте,
Бушап калды капчыклар.
Кызлар, әйдәгез егетләрне тапкырлыкта сынап карыйк.
Аларга табышмаклар әйтик.
**Сәидә:**
-Әйләндергән саен калыная (Йомгак)
-Зыр-зыр әйләнә,үзе килеп бәйләнә (Орчык)
Алим: Әйдәгез кызларны да  мәкаль әйтеп сынап карыйк.
**Кызлар бергә:** Без риза, әйдәгез.
-Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
-Илнең күрке - тынычлык.
-Икмәк - тормыш нигезе.
-Балалы кеше - бай була.
-Гаилә - бәхет ачкычы.
**Айзиля:** Егетләр, кызлар, әйдәгез җырлап биеп алабыз.
“Зәңгәр чәчәк” җырлы-биюле уен
Уйнау тәртибе
Балалар, кулга кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала чигүле кечкенә мендәр тотып, уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:
Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.
Туктап биеп-җырлап торалар, ә уртадагы бала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биеп йөри.Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.
Тезләнергә ипле  булыр -
Мендәреңне сал әле.
Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, аңа тезләнеп, кулын бирә. Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар. Уен алга таба шулай дәвам итә.
**Айзиля:** Җырлап-биеп күңел ачтык,
Күңелле булды кичә.
(Әни белән әти кайтып керәләр.)
**Әни:** Йә, ничек утырдыгыз?
**Талия:** Вакытның үткәнен сизми дә калдык. Әйдәгез хәзер бергәләп чәй эчеп алыйк, үз күчтәнәчен белән чәй эчсән, озын гомерле буласын дип әйтәләр бит.

**ТЕМА: Музейга сәяхәт**

Әзерләделәр: Абдуллина Г.А., Гараева З.Г.

**Максат:** Балаларны музей белән таныштыру, балаларда музейга карата кызыксыну уяту. Милли әйберләрнең үзләренә генә хас булган билгеләрен ачыклау. Балаларга эстетик тәрбия бирү, татар милли сәнгатенә мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.

**Кереш өлеш:**

**Тәрбияче:** Хәерле көн, балалар! Ничек хәлләрегез? Минем сезгә яңалыгым бар – безгә чакыру килде . Әйдәгез, бергә укып карыйк.

“Кадерле балалар! Мин, Ләйсән Рафкатовна, “Сандугач” балалар бакчасының “Әби-бабамның” йорты музеенның экскурсия алып баручысы . Сезне, 2022 нче ел мәдәни мирас елы булу уңаеннан, үзебезгә кунакка чакырам. Ләкин минем бер шартым бар. Музейга татар халык киемнәреннән килү таләп ителә” Барабызмы, балалар?

**Балалар:** Әйе.

**Балалар:** Ә костюмнарны каян алабыз?

Тәрбияче: Борчылмагыз, әйдәгез бергә тылсымлы сүзләрне әйтик һәм нәрсә булганын үзегез күрерсез.

Без, без, без идек.
Дүрт малай, дүрт кыз идек.
Базга төштек,бал ашадык
Келәткә кердек,май ашадык
Өйгә мендек, өйрә эчтек
Чишмәгә төштек,су эчтек
Әйләндек,әйләндек
Матур киемнәр кидек.
(Балалар бергәләшеп сикерәләр һәм татар халык киемнәреннән пәйда булалар)

**Тәрбияче**:Карагыз балалар безнең киемнәребез нинди матур.Әйдәгез бергәләп музейга юл тоттык.

**Экскурсия алып баручы:** Хәерле көн,балалар! Таныш булыйк, мин- Ләйсән Рафкатовна. Безнең “Әби-бабамның йорты” музеена рәхим итегез.

-Нәрсә соң ул музей? Кайсыгыз белә?

**Балалар**: Музейда элекке заман әйберләре саклана.
**Экскурсия алып баручы:** Әйе, дөрес. Музей- ул элекке заманда әби-бабайларыбыз кулланган әйберләр, савыт-саба, эш кораллары, кигән киемнәр саклана торган урын.
Музеебызның хуҗалары әби белән бабай. Әйдәгез әле, әби белән бабайның киемнәренә игътибар итик. Безнең әбиләребез һәрвакыт ак яулыктан һәм калфактан йөргәннәр. Ак яулык ул татар халкының чисталык билгесе булып саналган.

Әбиләребез үз куллары белән чиккән алъяпкычлар, бик матур күлмәкләр һәм бизәкле матур читекләр киеп йөргәннәр.
Карагыз әле бу калфакка! Нинди матур! Әбинең калфагын, бабайның түбәтәен алтын- көмеш укалы , аллы- гөлле җепләр белән гаҗәеп матур, нәфис милли бизәкләр төшереп чиккәннәр.
**Экскурсия алып баручы:** Балалар берәрегез калфак турында шигырь беләме?
**Гүзәл:** Энҗе калфак,үзе ап-ак
Бик килешә йөземә.
Калфагымның матурлыгын
Һәммәседә күрсеннәр
Энҗе калфак кигән кыз ул
Татар кызы дисеннәр.

**Экскурсия алып баручы:**Безнең бабайларыбыз милли бизәкләр белән чигелгән бик матур түбәтәйләр киеп йөргәннәр.
**Карим:** Ә мин түбәтәй турында шигырь беләм, сөйләп күрсәтим әле.
Түбәтәем түбәтәй
Укалыдыр читләре.
Шундый матур түбәтәйле
Малай булдым бит әле.
**Экскурсия алып баручы:** Күрегез әле, балалар. Бу нәрсә дип уйлыйсыз.
**Балалар:** Бишек.
**Экскурия алып баручы**:Әйе, бу бишек. Бишек ни өчен кирәк булган?
**Балалар :** Бишектә бала йоклатканнар
**Экскурсия алып баручы**: Әбиләребез сабый балаларны шул бишеккә салып тирбәткәннәр һәм бишек җырлары җырлап йоклатканнар.Ә сез бишек җырлары беләсезме?
**Әдил:** Мин беләм
Аллаху –аллаху,
Кәҗәләрне талга ку.
Кәҗә талны ашасын,
Бәби йоклый башласын.
**Экскурсия алып баручы:** Ул заманда хәзерге кебек җиһазлар күп булмаган. Йортта бердәнбер җиһаз булып өй түрендәге сәке саналган.Сәке түрендә самовар булган. Безнең әби-бабаларыбыз бик кунакчыл булганнар.Кунакны кайнар самовар чәе белән сыйлаганнар.
Кайсыгыз белә бу сәкегә утырып нишләгәннәр?

**Балалар:** иртәнге, көндезге һәм кичке ашны ашаганнар.Кич җиткәч сәке йоклау урыны булып та кулланылган.
**Экскурсия алып баручы** : Бүлмәнең бер почмагында менә шундый зур нәрсә урнашкан икән?
**Балалар:** мич урнашкан.
**Экскурсия алып баручы:** Бу зур мичтән гаилә учагы җылысы бөркелеп тора.Шушы зур мичтә, чуенда нәрсәләр пешерелде икән?
**Балалар:** Аш, ботка, ипи, коймак пешергәннәр. Мич өй эчен дә җылыткан.Мич башында җылыда кечкенә сабыйлар йоклаганнар.

**Экскурсия алып баручы:** Бу нәрсә икән кайсыгыз белә?
**Балалар:** лампа
**Экскурсия алып баручы**: Эйе, бу җиделе лампа
Элек электр утлары булмаган вакытта өй эчен җиделе лампа белән яктыртканнар.Аның җиде филтәсе бар.Лампага керосин салганнар һәм филтәнең төбен шунда төшергәннәр,чыра белән ут кабызганнар,керосин лампалары мич өстендә шүрлектә саклаганнар. Бу керосин лампасы яктысында әби-бабаларыбыз нишләгән?
**Балалар:**кич утырып чигү чиккәннәр, читек теккәннәр,чабата ясаганнар, бәйләү бәйләгәннәр,йон өрләгәннәр.
**Экскурсия алып баручы**:Татар авылының өй түрендә сандык булган. Сандыкта буыннан-буынга тапшырылган байлыклар саклана:
Сандык турында берәрегез шигырь беләме?
**Раяз:** Мин беләм
Серле сандык, матур сандык,
Кызыктыра мине күптәннән.
Әйдә карыйк ниләр калган икән
Истәлеккә безгә үткәннән.
**Балалар:** Сандыкта татар хатын-кызларының милли киемнәре, алъяпкычлар, читекләр, сөлгеләр сакланган. Сандык эчендә бер кечкенә генә тартмачык булган, бу тартмачыкта хатын-кызлар үзләренең бизәнү әйберләрен саклаганнар. Карагыз әле, балалар, монда беләзекләр, чулпылар, колак алкалары , мәрҗәннәр бар.

**Тәрбияче:** Без буген музейда бик куп истәлекле әйберләр курдек. Музейга чакыруыгызга рәхмәт сезгә.

Ә хәзер, балалар, әйдәгез бер уен уйнап алыйк. Ләйсән Рафкатовна сөйләгәннәрдән нәрсәләр истә калды икән сездә. Үзебезне тикшереп карыйк әле. “Бу нәрсә”уены.

Бишек, сәке, мич, лампа, сандык, калфак, түбәтәй, читек рәсемнәре төшерелгән карточкалар. Аларны рәсемле ягы белән аска каратып салырга. Бала бер карточканы сайлап ала, ләкин анда нәрсә икәнен карамый. Башка балаларга күрсәтелә һәм алар, бу әйбернең исемен атамыйча, ана хас булган үзенчәлекләрен атыйлар, тасвирлама бирәләр. Уенчы аларнын ярдәме белән карточкада нәрсә ясалганын белергә тиеш.

**Тәрбияче:** Бик яхшы, балалар! Сез уенда җиңел генә отып чыктыгыз. Димәк, бик игътибарлы булгансыз. Балалар, сез милләтегезнең дәвамчылары. Татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен саклап яшәсәгез иде!

**“Экология иленә сәяхәт “(мәктәпкә әзерлек төркеме)**

Әзерләделәр: Яруллина А.К., Галеева Р.Р.

**Максат**: Балаларда мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү, сүзлекне баету, зирәклек, күзәтүчәнлек, тапкырлык тәрбияләү.

**Шөгыль барышы**:

Телефон шалтырый.

**Тәрбияче**: Хәерле көн балалар, безгә кемдер шалтырата.

**Белмәмеш:** Хәерле көн балалар! Минем сезгә бер үтенечем бар иде. Мине экология иленә сәяхәткә чакырдылар, ә мин анда ничек барырга һәм үземне ничек тотарга икәнлеген белмим. Минем бик күп төрле кызыклы мәгълүматләр беләсем килә. Балалар сез миңа ярдәм итә аласызмы?

**Тәрбияче**: Балалар, белмәмешкә ярдәм итәбезме?

**Балалар**: Эйе.

**Тәрбияче:** Ярар, белмәмеш, без сиңа ярдәм итәрбез, ләкин сиңа безнең “Сандугач “ балалар бакчасына килергә кирәк булачак. Без сине көтеп калабыз.

**Белмәмеш:** Яхшы, балалар, хәзер килеп җитәм.

Белмәмеш килә.

**Белмәмеш**: Исәнмесез, балалар.

**Балалар:** Исәнме, Белмәмеш.

**Тәрбияче**: Белмәмеш, экология иленә сәяхәткә барганчы, безгә күп төрле уеннар уйнап белемебезне арттырырга тәкъдим итәм .

**Тәрбияче**: Балалар сәяхәткә чыкканчы табигатьтә үзеңне ничек тотарга тиеш икәнен шушы шакмак ярдәмендә искә төшереп китик әле.

1. **“Шакмак уены”.**




**Максат**: Балаларның сөйләм телен үстерү, табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру; шәфкатьлелек тәрбияләү.

Шакмакның һәрбер ягында табигатьтә узеңне ничек тоту кагыйдә рәсемнәре сүрәтләнгән. Балалар шакмакны әйләндерәләр, өскә чыккан рәсемне аңлатып бирәләр.

**2.”Урмандагы могҗиза” уены**

**Максат**: Сөйләмдә үсемлек, кыргый хайван исемнәрен дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү.

Балаларга табышмаклар әйтелә, дөрес җавап бирүче бала рәсемне мольбертка элеп куя.

Үсемлек дөньясы турында табышмаклар:
1.Җәен киенә, кышын чишенә (Агач)
2.Нечкә яшел сабакта
Юл буенда шар үскән.
Кай арада җил искән,
Ак шар очкан да киткән.(Тузганак)
3.Ап-ак күлмәген кигән,
Күлмәгенә тап тигән.
-Җәй башында җиләгемне
Авыз итәрсең,-дигән.(Каен)
4.Кигән ап-ак эшләпә
Төшереп кашына ук,
Эшләпәсен салдырсаң,
Каш түгел,башы да юк.(Гөмбә)
5.Төрле-төрле төстә алар,
Бу төсләр каян килгән?
Хушбуй исе аңкыталар,
Кем аны сөртеп йөргән?(Чәчәкләр)
6. Ул өстенә җәй дә, кыш та
Энәле күлмәк кия.
Шулай да аны әнкәсе:
“Йомшагым”,-диеп сөя.(Керпе)
7.Килә бер батыр атлап, аягын баса лап-лап,
Урманда йөри, умартадан бал көри.(Аю)



**3. “Кайсы агачның яфрагы” уены**.

**Максат**: Балаларда җөмлә төзү, җөмләдә сүзләрнең мәгънәләрен дөрес аңлап урынлы итеп куллана белергә өйрәтү.

Балаларга төрле яфрак төшкән карточкалар бирелә, бала кайсы яфрак нинди агачтан икәнен танып һәм аның сыйфатларын әйтергә тиеш. Мәсәлән: Бу каен агачы, каен агачының алкалары бар.



**4. “Кем кайда яши” уены**.

**Максат**: Хайваннарның яшәү урыннарын әйтергә, табигатьне, тереклекне хөрмәт итәргә, яратырга өйрәтү.

**Тәрбияче**: Балалар кыргый хайваннар кайда яшиләр?

**Балалар**: Урманда .




**Тәрбияче**: Урманда яши торган хайваннарны әйтеп китик әле.

(Бүре, аю, төлке, куян, керпе, поши)

**Тәрбияче:** Ә йорт хайваннары кайда яшиләр?

**Балалар**: Авылда.

**Тәрбияче**: Дөрес, балалар, ә авылда нинди хайваннар яши?

(Ат, сыер, дуңгыз, сарык, кәҗә)

Һәрбер хайванның үз яши торган урыны бар, әйдәгез хәзер сез аларны үзләренең яши торган урыннарына урнаштырырсыз.

(балалар такта янына чыгып хайваннарны үз урыннарына урнаштыралар)

**5. Лото “Ел фасыллары”**



**Максат**: Сөйләмдә исемнәрне куллана белү күнекмәләрен үстерү һәм сүзлекне баету.

Балаларга 4 төрле ел фасыллары төшкән карточкалар эләшелә. Һәр ел фасылы турында әңгәмә алып барыла.

**6.”Булсаң зирәк- әйт тизрәк“ уены.**

**Тәрбияче:** Балалар безгә сорауларга җавап бирергә кирәк. Һәрбер дөрес җавап өчен сезгә хәреф төшерелгән шакмак бирелер, шул шакмаклардан без сезнең белән сүз җыярга тиеш булырбыз.

1. Ни өчен урманда чәчәкләрне эзәргә ярамый? (чөнки, чәчәкләр орлык биреп өлгерә алмый)




2. Ни өчен урманда янгын чыгу хәтәр? (чөнки урман янып бетергә мөмкин)
3. Урманда чүп-чар ташлап калдырырга ярыймы? (юк, үзең белән пакетка җыеп алып китергә кирәк.)
4. Ни өчен кырмыска ояларын җимерергә ярамый (чөнки кырмыскалар

урманга бик күп файда китерәләр)

5. Суалчаннар нинди файда китерәләр? (җирне йомшарталар)

6. Ни өчен агулы гөмбәләрне юкка чыгарырга ярамый (чөнки алар кайбер кыргый хайваннар өчен дару булып торалар)




7. Ауга чыгарга ярыймы? (юк, чөнки кыргый хайваннарны юкка чыгару катгый тоела)

8. Ни өчен кыш көне кошларны ашатырга кирәк? (чөнки кыш көне кошларга азык табуы бик кыен)

**Тәрбияче:** Әфәрин, балалар. Белмәмеш, балалар белән сиңа булыша алдыкмы?

**Белмәмеш:** Әйе. Күңелле, кызыклы уеннар уйнап , мин күп кенә мәгълүматлар тупладым. Рәхмәт сезгә, балалар.

**Тәрбияче:** Белмәмеш, без сине бакчабызның табигать почмагына сәяхәткә чакырабыз.

**Уртанчылар төркемендә интегральләшкән шөгыль**
**“Көз бабайда кунакта”**

Тәрбияче: Гарипова Л.Р., Зигакншина Л.И.

**Максатлар**: Балаларны яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр белән таныштыруны, алар турындагы белемнәрне тирәнәйтү сыйфатларын билгеләүне дәвам итү.

**Өйрәнгән сүзләрне сөйләмдә активлаштыру**: яшелчә бакчасы, түтәл, озынча, түгәрәк, уңыш, ачы.

**Методик алымнар**: әңгәмә, уен, сорауларга җавап бирү.

**Күрсәтмә материал**: яшелчәләр (чөгендер, кишер, кыяр, суган, помидор, кәестә, баклажан), җиләк-җимешләр (алма, груша, слива), яшелчә һәм җиләк-җимеш карточкалары.



**Таратма материал**: маскалар.

**Җиһазлар:** җиләк-җимеш, яшелчәләр салынган кәрзиннәр.

**Үткәрү урыны: төркем бүлмәсе.**

**Шөгыль барышы:**

**Оештыру өлеше:** Төркем бүлмәсе төрле төстәге яфраклар белән бизәлгән. Хәерле көн, балалар. Әйдәгез, бер-беребез белән исәнләшеп алыйк әле.



-Исәнмесез!
Кулларны без тотындык
Бер-беребезгә елмайдык.
Җылы китте кулларга
Рәхәт булды дусларга.

Балалар, күрегез әле, табигатьтә нинди матурлык! Көз - табигатьнең иң гүзәл мизгеледер.

(Тәрбияче кулында хат).

Балалар, мин бүген бер хат алдым. Аны җылы якка китүче кошлар калдырдылар.Тыңлап карагыз әле.



Тәрбияче укый: Кадерле балалар! Бакчамда яшелчәләр, җиләк-җимешләр өлгерде. Шуны җыеп алырга булышмассызмы икән? Көз бабай. Балалар, булышабызмы көз бабайга? (Балалар җавабы).

-Әйдәгез, хәзер менә бу түтәл янына киләбез. Түтәлдәге яшелчәләрне, агачтагы җиләк-җимешләрне кәрзиннәргә аерып тутырабыз.

-Ә хәзер күпме булганын бергәләп санарбыз һәм язып куярбыз.

Ял итү: “Бар безнең бакчабыз” (УМК) (Балалар түгәрәккә баса, яшелчә маскалары кидерелә)

Бар безнең бакча

Анда кишер (суган, помидор, кыяр, чөгендер) үсә. (Яшелчә исемен әйткән бала түгәрәккә чыгып бии).



Уен “Биредә нәрсә юк?” (Тәрбияче өстәмә яшелчәләр куя).

Балалар, болар нәрсәләр? (яшелчә һәм җиләк-җимеш.)

Яшелчәләр сезнең белән качышлы уйнарга телиләр. Уйныйсызмы? (Балалар игътибар белән карыйлар, тәрбияче тукыма белән яшелчәләрне каплый. Шул арада бер яшелчәне яки җиләк-җимешне алып куя).

-Биредә нәрсә юк?

-Булдырдыгыз, балалар! Сез бик игътибарлы икәнсез.

-Ә хәзер мин сезгә “Серле кәрзин” уенын уйнарга тәкъдим итәм.

-Балалар, көз көне бакчада нәрсәләр өлгерә? (Яшелчә һәм җиләк-җимешләр)

-Ә минем кулымдагы кәрзиндә нәрсәләр бар? (кыяр, помидор, чөгендер, суган, кишер, алма, груша)



Кәрзин өсте каплана. (Бер-бер артлы балалар чыга, кулны тыгып нәрсә икәнен әйтә). Иптәшләренә күрсәтә һәм сыйфатларын билгелиләр.

Суган нинди төстә? (суган сары) Ул нинди? (Түгәрәк, ачы, елата). Суган кайда үсә? (Суган түтәлдә үсә).

Кишер нинди төстә? (Кишер кызгылт-сары төстә). Ул нинди? (тәмле, озынча). Кишер кайда үсә? (Кишер түтәлдә үсә). (Кыяр, помидор, алма, чөгендер, груша)

Булдырдыгыз, балалар! Сез барлык яшелчә һәм җиләк-җимешнең үзлекләрен әйтеп бирдегез.

Ә Көз бабайга булышкан өчен ул сезгә күчтәнәч җибәргән. (Кәрзин төбендә алмалар)